

Кадошкино районы Потмы авылында Дания Амин кызы Еналеева туып-үскән. Ул гомерен мәгарифкә багышлаган кеше. Мордовиянен Атказанган мәгариф хезмәткәре.

Потмы болыннарын басып ала
Иса суы язын, кин ташу.
Артугылда шомырт чәчәк ата,
Хуш исләрдән әйләнер башын.
Ожмах кебек синен табигатен,
Урманында шаулый усаклар,
Туган ягым исләремнән чыкмый,
Кайда гына калды ул чаклар? Синен яргаланган сукмакларын
Күз алдымнан бер дә китмиләр,
Су буенда монлы камышларын
Мәнге бетмәс койне койлиләр.
Сагындыра газиз авылкаем,
Тошләремә кереп уята,
Вакыт тарта туган нигезләргә,
Уйлата да узе, елата.
Булган югалтулар хәтерләрдә,
Үткәннәрдән үзәк озелә.
Узган еллар, гүя очкан кошлар,
Күнел кырларына тозелә.
Хыялым бар: Ташлык янындагы
Чишмә суын барып багарга.
Еллар үтүенә карамастан,
Тиеш әле ул су агарга...
Якташларым! Күп сәламнәр сезгә,
Тормышыгыз булсын бәласыз,
Ботенегез мина шундый якын,
Кадерлеләр булып каласыз.